**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6922**
**21.10.2021**

«Автокаланың яшь
эшмәкәре-2021» конкурсын
әзерләү һәм үткәрү турында

Яшьләр арасында эшмәкәрлекне популярлаштыру, актив яшьләрне ачыклау һәм бүләкләү максатында һәм Башкарма комитетның 2019 елның 30 октябрендәге 5586 номерлы карары белән расланган «2020-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә Яр Чаллы шәһәрендә «Автокаланың яшь эшмәкәре-2021» конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс турында нигезләмәне 1 нче кушымтда каралганча;

2) конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын 2 нче кушымтда каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны әзерләү һәм үткәрү чыгымнарын финанслауны 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 112 800,00 (бер йөз унике мең сигез йөз) сум 00 тиен күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 21 октябрендәге
6922 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Автокаланың яшь эшмәкәре-2021»
конкурсы турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәрендә «Автокаланың яшь эшмәкәре-2021» конкурсын (алга таба – конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели. Конкурсны оештыручы булып Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе тора.

2. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурсны үткәрү тәртибен аңлата;

2) конкурста катнашучыларның заявкаларын кабул итә;

3) тәкъдим ителгән проектлар нигезендә конкурсның жюри әгъзалары составын формалаштыра;

4) конкурста катнашучылар исемлеген раслый;

5) конкурс финалын үткәрү көнен билгели.

2 бүлек. Конкурсның максаты һәм бурычлары

3. Конкурсның максаты булып яшьләр арасында нәтиҗәле тормыш стратегиясе буларак эшмәкәрлекне популярлаштыру тора.

4. Конкурсның бурычлары:

1) илнең икътисадый-социаль прогрессының мөһим факторы буларак, яшьләр эшмәкәрлегенең позитив имиджын формалаштыру һәм популярлаштыру;

2) эшмәкәрлек эшчәнлеге алып баручы актив һәм сәләтле яшьләрне ачыклау һәм бүләкләү;

3) яшьләр арасында үрнәкләр булдыру;

4) яшьләр эшмәкәрлеген үстерү өчен шартлар тудыру, яшь эшмәкәрләр базасын формалаштыру.

3 бүлек. Конкурста катнашучылар

5. Конкурста катнашуга Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче 18 дән 35 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданнары кертелә. Конкурста шәхси эшмәкәрләр, бер компанияне гамәлгә куючылар яки аның җитәкчелеге вәкилләре булган берничә физик зат катнаша ала. Конкурста бергәләп катнашучы һәм үзләренең уртак бизнесларын тәкъдим итүче мондый затлар төркеме бер катнашучы буларак карала.

6. Конкурста катнашучы түбәндәге шартларның берсен канәгатьләндерергә тиеш:

1) оештыру-хокукый формасына һәм милек формасына бәйсез рәвештә, законда билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән шәхси эшмәкәр, юридик затны гамәлгә куючы (гамәлгә куюда катнашучы) булырга;

2) оештыру-хокукый формасына һәм милек формасына бәйсез рәвештә, законда билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затның

башкарма органы составына керергә;

3) үзмәшгуль булырга.

7. Түбәндәге компания вәкилләре конкурста катнашуга кертелми:

1) Россия Федерациясе законнары белән тыелган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы;

2) алкогольле һәм спиртлы продукция, сыра һәм аның нигезендә җитештерелгән эчемлекләр, шулай ук тәмәке, тәмәке эшләнмәләре, тәмәке кирәк-яраклары җитештерү һәм сату эшчәнлеген гамәлгә ашыручы;

3) азартлы уеннар оештыручы яки үткәрүче.

## 4 бүлек. Конкурсны үткәрү сроклары һәм тәртибе

8. Конкурс этаплап үткәрелә:

1) I этап – читтән торып. 2021 елның 30 октябренә кадәр катнашучылар тарафыннан Chelnyanp@gmail.com электрон адресы буенча оештыру комитетына заявкалар бирелә, белешмәләр өчен телефон – 8-951-068-00-77. Оештыру комитеты заявкаларны карап тикшерә һәм II этапта катнашучыларны билгели. Заявканы карап тикшергәндә оештыру комитеты тапшырылган материалларның тулылыгын тикшерә. Гариза бирү срокларын бозу аны конкурста катнаштырудан кире кагу өчен нигез булып тора;

2) II этап – урында. Конкурста катнашучылар тарафыннан бизнес-проектларны жюри әгъзаларына презентацияләү. 2021 елның 16 ноябрендә үткәрелә;

3) финал – җиңүчеләрне игълан итү һәм бүләкләү тантанасы. Көне II этап тәмамланганнан соң оештыру комитеты тарафыннан билгеләнә.

## 5 бүлек. Конкурсның эчтәлеге

9. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) «Ел ачышы»;

2) «Уңышлы старт»;

3) «Социаль эшмәкәрлек»;

4) «Иң яхшы бизнес идея»;

5) «Автокала эшмәкәре».

10. Конкурста катнашуга заявка түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралганча, катнашучыны теркәү формасын;

2) әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралганча, теркәү формасына кушымтаны;

3) әлеге нигезләмәгә 3 нче кушымтада каралганча, бизнес-планны.

## 6 бүлек. Конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары һәм тәртибе

11. Барлык номинацияләрдә дә конкурста катнашучыларны бәяләү өчен гомуми критерийлар булып тора:

1) эшмәкәрлек рухы – нәтиҗәле бизнес-идея булдыру, аны үстерү һәм тормышка ашыру сәләте, базарга гына ияреп барырга түгел, ә аның үзгәрү тенденцияләрен алдан күрә белү сәләте, стратегик һәм тактик максатлар куя белү һәм аларга ирешү;

2) идарә итү сәләте – бердәм һәм нәтиҗәле команда булдыру, хезмәткәрләрне үз идеяләрең белән мавыктыру һәм аларның потенциалын ачу сәләте;

3) инновацион алым – яңа товарлар һәм хезмәтләр эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә иҗатка һәм новаторлыкка ориентация, компаниядә инновацияләр культурасын стимуллаштыру;

4) бизнесның социаль әһәмияте – яңа эш урыннары булдыру; хезмәткәрләрнең хезмәтләрен хөрмәтләү, тану, аларның компания тормышында актив катнашуларын бүләкләү; яшьләрне хезмәт эшчәнлеге процессына җәлеп итү, беренче чиратта кирәкле

товарлар һәм хезмәтләр күрсәтү яки халыкның социаль якланмаган катламнарына ориентация;

5) финанс күрсәткечләре – бизнес үсешенең тотрыклылыгы турында раслаучы рентабельлек һәм үсеш күрсәткечләренең уңай динамикасы;

6) эшмәкәр шәхесенең бөтенлеге – кыенлыкларны җиңеп чыгу, куркыныч ситуацияләр белән идарә итү, билгесезлек шартларында дөрес карарлар кабул итү, белем дәрәҗәсе һәм үз-үзеңне үстерү сәләте, хезмәткәрләр һәм конкурентлар тарафыннан танылу һәм хөрмәт.

12. Конкурста катнашучылар жюри әгъзалары тарафыннан бәяләү критерийлары нигезендә бәяләнәләр:

| № т/б | Критерий | Максималь бәя |
|---|---|---|
| 1. | Эшмәкәрлек рухы | 20 |
| 2. | Идарә итү сәләте | 10 |
| 3. | Инновацион алым | 20 |
| 4. | Бизнесның социаль әһәмияте | 20 |
| 5. | Финанс күрсәткечләре | 10 |
| 6. | Эшмәкәр шәхесенең бөтенлеге | 20 |
| Максималь йомгаклау билгесе | | 100 |

7 бүлек. Конкурска йомгак ясау

13. Һәр номинация буенча җиңүчеләр иң зур уртача баллга ия катнашучылар арасыннан жюри әгъзалары тарафыннан билгеләнә. Уртача балл жюри әгъзалары тарафыннан тиешле заявкага куелган баллар суммасын әлеге заявканы карап тикшергән жюри әгъзалары санына бүлеп исәпләнә. Берничә претендентның уртача баллары тигез булган очракта, җиңүчеләрне сайлау жюри әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш нигезендә үткәрелә.

14. Жюри эшенең нәтиҗәләре беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

15. Жюри эшенең нәтиҗәләре буенча конкурсның бер абсолют җиңүчесе һәм һәр номинациядә берәр җиңүче билгеләнә. Җиңүчеләр дипломнар һәм түбәндәге акчалата призлар белән бүләкләнә: конкурсның абсолют җиңүчесе – утыз мең сум; номинацияләрдә җиңүчеләр – унбиш мең сум.

16. Конкурста җиңүчеләр эшмәкәрлек буенча региональ һәм бөтенроссия конкурсларында катнашырга тәкъдим ителә.

17. Конкурста җиңүчеләрне игълан итү һәм бүләкләү конкурс финалы тантанасы барышында башкарыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

«Автокаланың яшь
эшмәкәре-2021»конкурсы
турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Катнашучыны теркәү формасы

| Конкурста катнашучы турында мәгълүмат | |
|---|---|
| Фамилиясе, Исеме, Атасының исеме | |
| Номинация | ☐ «Ел ачышы»;<br>☐ «Уңышлы старт»;<br>☐ «Социаль эшмәкәрлек»<br>☐ «Автокала эшмәкәре»<br>☐ «Иң яхшы бизнес идея» |
| Туу датасы | |
| Вазыйфасы, эш урыны | |
| Белеме (югары, урта һөнәри, урта гомуми) | |
| Тармакта, коллективта гомуми эш стажы | |
| Хезмәт эшчәнлеге / соңгы 3 елда белем алуы:<br>керү/тәмамлау ае һәм елы;<br>вазыйфасы / уку формасы;<br>оешманың исеме һәм координаталары. | |
| Өй адресы, телефон, электрон почта адресы: | |
| Паспорт белешмәләре (серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән, бүлекчәнең коды, туган урыны) | |
| Оешма турында мәгълүмат (әгәр кулланылса) | |
| Исеме | |
| Оештыру-хокукый формасы | |
| ИНН | |
| Төп эшчәнлек юнәлеше, җитештерелә торган продукция / күрсәтелә торган хезмәтләр | |
| Адрес, предприятие индексы, телефон, факс, e-mail: | |

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм ____________________
Мин «Автокаланың яшь эшмәкәре-2021» конкурсы шартлары белән килешәм

| ____________________ | ________________________ | ____________________________ |
|---|---|---|
| Дата/ | Имза | Ф. И.А.и. |

«Автокаланың яшь
эшмәкәре-2021» конкурсы
турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Номинацияләр өчен теркәү формасына кушымта эчтәлеге

| № т/б | Исеме | Тәкъдим ителә торган эчтәлек |
|---|---|---|
| 1. | Катнашучы | Катнашучының эшмәкәрлек сыйфатларын, аның куркыныч ситуацияләр белән идарә итә белүен, билгесезлек шартларында карарлар кабул итү сәләтен, эш тәҗрибәсен, махсус күнекмәләрен, төп казанышларын һ. б. тасвирлагыз |
| 2. | Бизнес барлыкка килү | Катнашучы компаниясенең тарихын тасвирлагыз. Компанияне булдыру өчен башлангыч идея һәм аның яңалык дәрәҗәсе, компанияне булдыру/эшләтеп җибәрү һәм үстерү процессы катлаулылыгы дәрәҗәсе, катнашучы җиңеп чыккан әһәмиятле финанс куркынычлылыгы, башка җитди каршылыклар тасвирламасын кертегез. |
| 3. | Новаторлык алымы | Катнашучының ничек төп продуктларны яки хезмәтләрне эшләүгә һәм гамәлгә кертүгә иҗади һәм инновацион якын килүен тасвирлагыз. Катнашучы бизнесының уникаль үзенчәлекләре, компания һәм аның конкурентлары арасындагы төп аермалар тасвирламасын кертегез. |
| 4. | Киләчәккә планнар | Катнашучының кыска сроклы һәм озак сроклы планлаштыру күнекмәләрен демонстрацияләүче, компания киләчәгенә мөнәсәбәтле планнарын тасвирлагыз. |
| 5. | Бизнес белән идарә итү | Компания белән идарә итү өлкәсендә катнашучы казанышларының, компания үсешенә ярдәм итүче стандарт булмаган һәм/яки нәтиҗәле идарә итү идеяләренең һәм карарларының конкрет мисалларын китерегез. Аларның эш тәҗрибәсен, махсус күнекмәләрен һәм төп казанышларын күрсәтеп, компаниянең икедән артык булмаган төп ике җитәкчесен (катнашучыдан тыш) тасвирлагыз. |
| 6. | Социаль җаваплылык | Компаниядәге атмосфераның хезмәткәрләрнең инициатива күрсәтүенә, аларның һөнәри һәм шәхси үсешенә ничек ярдәм итүен тасвирлагыз. Кушымтага компаниядә социаль климатны яхшырту буенча катнашучының инициативалары тасвирламасын, компаниянең хәйрия акцияләрендә һәм җирле һәм/яки региональ дәрәҗәдәге социаль программаларда катнашу мисалларын кертегез. |

______________________ ______________________ ______________________

Дата/ Имза Ф. И.А.и.

«Автокаланың яшь
эшмәкәре-2021» конкурсы
турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

Бизнес-план эчтәлеге:

1. Проектны сайлау һәм нигезләү.
2. Проект схемасы.
3. Уйлап табу мәсьәләләрен чишү алгоритмы.
4. Җитештерү технологиясе:
1) җитештерү этапларын тасвирлау;
2) комплектлаштыру.
5. Проектны икътисадый нигезләмәү.
6. Реклама.
7. Контроль һәм сынау.

Искәрмә: проектның эчтәлегенә туры китереп, бизнес-планга слайдлар куела.